РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

Тел.:8(84364)2-63-02, факс:8(84364)2-63-04,e-mail:Kukmor.Kuk@tatar.ru,www:kukmor.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 август 2026 г. № 121

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм куллану тәртибен раслау турында» 2022 елның 20 декабрендәге 63 номерлы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Элемтә турында» Федераль законның 6 статьясына һәм «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 23 июлендәге 251-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 20 декабрендәге 63 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм куллану тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 2 бүлегендәге 2.4 – 2.4.6. пунктларын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосалар чикләрендә, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 08 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, түбәндәгеләр тыела:

2.4.1. Автомобиль юлын төзү, үзгәртеп төзү, капиталь төзекләндерү, төзекләндерү һәм карап тоту, шулай ук юл хезмәте объектларын, элемтә

линияләрен һәм элемтә корылмаларын урнаштыру белән бәйле булмаган эшләр башкару;

2.4.2. Автомобиль юлына хезмәт күрсәтү, аны төзү, үзгәртеп төзү, капиталь төзекләндерү, төзекләндерү һәм карап тоту өчен каралмаган һәм юл хезмәте объектларына, элемтә линияләренә һәм элемтә корылмаларына карамый торган биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм башка объектлар урнаштыру;

2.4.3. Автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны карап тоту яки автомобиль юлларын, аның участокларын ремонтлау буенча эшләрдән тыш, җир кишәрлекләрен сөрү, үлән чабу, урман үсентеләрен һәм башка күпьеллык башка утыртмаларны кисү һәм зыян китерү, чирәмне һәм грунтны алу;

2.4.4. Хайваннарны көтү, шулай ук аларны автомобиль юллары хуҗалары белән килешенгән махсус билгеләнгән урыннардан тыш автомобиль юллары аша куып чыгару;

2.4.5. Техник регламентлар таләпләренә һәм (яисә) юл хәрәкәте иминлеге турында норматив хокукый актларга туры килми торган реклама конструкцияләрен урнаштыру;

2.4.6. Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә яки юл эшчәнлеген гамәлгә ашыруга катнашы булмаган мәгълүмати щитлар һәм күрсәткечләр урнаштыру.»;

1.2. Тәртипнең 4 бүлегендәге 4.2 пунктның икенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Тәртипнең 4.2 пунктында каралган килешүдә капиталь төзелеш объектларын, юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектларны, юл сервисы объектларын төзүне, реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны, шул исәптән инженерлык коммуникацияләрен, элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын сузуны, күчерү, үзгәртеп коруны, реклама конструкцияләре, мәгълүмати щитлар һәм күрсәткечләр урнаштыруны, ремонт эшләрен башкаруны гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле техник таләпләр һәм шартлар булырга тиеш.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче: В.Н. Андреев